# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

29 март 2024 ел №2

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Түбән Чыршылы авылында 2024 елда үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгының 19.03.2024 «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында" 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, "Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча "Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елда билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы карарларына түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

1) Түбән Чыршылы торак пунктында традицион җирләү урыннарын төзекләндерү ремонтлау, коймалар тоту (зират өчен хуҗалык бинасы урнаштыру, төзү материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Түбән Чыршылы торак пункты территориясен төзекләндерү (махсус техникага хезмәт күрсәтү МТЗ - 82.1 тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

3) торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Түбән Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

4) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын ремонтлау (Түбән Чыршылы торак пунктында янгын сүндерү сулыкларын төзү, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов